СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.10.2021 г. Заинск № 171

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында Нигезләмә хакында**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрүне тәртипкә салу максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән расланган Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. «Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмә хакында» 2015 елның 16 октябрендәге 21 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Л.Г. Ананьевага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Советының
«07» октябрь 2021 ел
171 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмә**

1. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендәге әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе һәм шартлары билгеләнә (алга таба – конкурс).

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында конкурс нигезендә биләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларының түбәндәге исемлеге билгеләнә:

- муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары;
- муниципаль хезмәтнең төп вазифалары.

3. Әлеге Нигезләмә Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

4. Конкурс гражданнарның үз сәләтләре һәм һөнәри әзерлекләре нигезендә муниципаль хезмәткә бертигез дәрәҗәдә керү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә конституцион хокукын тәэмин итә.

5. Җирле үзидарә органнарында конкурс муниципаль хезмәтнең вакантлы (муниципаль хезмәткәр тарафыннан биләнмәгән) вазыйфасы тиешле органда булганда җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча игълан ителә.

6. Конкурс үткәрелми:

1) сайланулы муниципаль вазыйфа биләүче зат вәкаләтләрен үтәүне турыдан-туры тәэмин итү өчен гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә;

2) вакытлы хезмәт килешүе төзегәндә;

3) җирле үзидарә органы бетерелүгә, аның штаты кыскаруга (муниципаль хезмәт вазыйфасы кыскаруга) бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр башка вазыйфага билгеләнгәндә;

4) билгеләнгән тәртиптә төзелгән кадрлар резервында торучы муниципаль хезмәткәр (граждан) муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә.

Конкурс муниципаль хезмәтнең аерым муниципаль вазыйфаларына билгеләнгәндә үткәрелмәскә мөмкин, алар буенча вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле.

7. Конкурс муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

8. Конкурста катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүче, муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр сыйфатында "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 13 статьясында билгеләнгән шартлар булмаганда, Россия Федерациясе гражданнары ия.

9. Җирле үзидарә органы тарафыннан конкурс уздыру турында һәм анда катнашу өчен документлар кабул итү турында хәбәр «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

10. Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрү турында хәбәрдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) вакантлы вазыйфаның тулы исеме;

2) әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга куела торган таләпләрне үз эченә алган конкурсны уздыру шартлары;

3) конкурсны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында белешмәләр;

4) әлеге Нигезләмәнең 10 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документлар кабул итүнең срогы;

5) хезмәт килешүе проекты;

6) конкурс турында тулырак мәгълүмат чыганагы турында белешмәләр (телефон, факс, электрон почта, электрон адрес).

11. Конкурсны үткәрү турында белдерү конкурс уздырылган көнгә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча бастырыла.

12. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы конкурс комиссиясенә тапшыра:

1) шәхси гариза;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосурәт белән;

3) паспорт күчермәсе яки аны алмаштыручы документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

4) кирәкле һөнәри белем, квалификацияне һәм эш стажын раслаучы документлар:

- хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән мәгълүмат, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

- белем һәм квалификация турында документлар, гыйльми дәрәҗә бирелү турында документлар, гыйльми исем, нотариаль яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәтләре тарафыннан расланган документлар күчермәләре;

5) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулаучы авыру булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе.

13. Үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын башкара торган җирле үзидарә органында конкурста катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр эшкә алучының вәкиле исеменә гариза бирә.

Җирле үзидарәнең башка органында үткәрелә торган конкурста катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр әлеге җирле үзидарә органына яллаучы вәкиле исеменә гаризаны, үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торган җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан имзаланган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча анкетаны, фотосурәт белән, тапшыра.

14. Гариза биргән затка документларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, расписка бирелә.

15. Муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турында законнарда билгеләнгән чикләүләр булганда граждан конкурста катнашуга кертелми.

Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнаштырудан баш тартылган очракта, граждан әлеге карарга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашучы теләсә кайсы вакытта үз гаризасын кире алырга мөмкин.

16. Тәкъдим ителгән документларны конкурс комиссиясе секретаре кабул итә. Әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән документлар конкурс үткәрү турында хәбәр басылып чыккан көннән соң 20 көн эчендә конкурс комиссиясенә тапшырыла.

17. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

18. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, хезмәт тәртибенә куелган таләпләрнең үтәлешен тикшерү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

19. Конкурс гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча үткәрелә.

20. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар үткәрү өчен Зәй муниципаль районы башлыгы карары белән конкурс комиссиясе төзелә.

21. Конкурс комиссиясе составына җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм (яисә) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән муниципаль

хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәләрдән, юридик (хокукый) бүлекчәдән һәм вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрелә торган бүлекчәдән), шулай ук бәйсез экспертлар буларак чакырыла торган башка оешмалар вәкилләре керә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.

22. Конкурс комиссиясе рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм 6 комиссия әгъзасыннан тора.

Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары конкурс комиссиясе рәисе вазыйфаларын ул булмаган очракларда башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе утырышларына материаллар әзерләүне тәэмин итә, конкурс комиссиясе әгъзаларына утырышны чакыру турында хәбәр итә, комиссия әгъзаларына көн тәртибе турында хәбәр итә, гаризалар, документларны кабул итә һәм терки, конкурс комиссиясе карарлары проектларын әзерли, конкурс нәтиҗәләре турында кандидатларга хәбәр итүне тәэмин итә, конкурс комиссиясе рәисе кушуы буенча башка функцияләрне башкара.

23. Комиссия составы конкурс комиссиясе кабул иткән карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеген булдырмаслык итеп формалаштырыла.

24. Тәкъдим ителгән документлар нигезендә конкурс комиссиясе кандидатларны конкурста катнашуга кертү турында карар кабул итә.

25. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар биргән белем, муниципаль, граждан яисә башка дәүләт хезмәте узуы, башка хезмәт эшчәнлеген башкаруы турында документлары нигезендә бәяли.

Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә конкурс комиссиясе вакантлы вазыйфага карата тиешле квалификация таләпләреннән, вазыйфаи инструкция таләпләреннән, шулай ук муниципаль хезмәт турында законнарда билгеләнгән нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

26. Кандидатларны тикшерү һәм сайлап алу конкурс комиссиясе утырышларында гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе утырышы муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына кимендә ике кандидат булса һәм комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карарлары утырышта катнашучы әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

27. Конкурс комиссиясе карары кандидаттан башка кабул ителә һәм аны муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына билгеләү яисә бу вазыйфага билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим итү характерына ия булган, җирле үзидарә органының кадрлар резервына муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатларына югары бәя бирелгән кандидатны кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

28. Конкурс комиссиясе карары һәм конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашкан комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя.

29. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле хезмәт килешүе төзи һәм конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан сайлап алынган кандидатларның берсен муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына билгели.

Әгәр конкурс комиссиясе тарафыннан җирле үзидарә органының кадрлар резервына муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче булмаган кандидатны кертү турында карар кабул ителсә, күрсәтелгән затның ризалыгы белән аны муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен әлеге органның кадрлар резервына кертү турында җирле үзидарә органы акты чыгарыла.

30. Әгәр конкурс үткәрү нәтиҗәсендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, җирле үзидарә органы җитәкчесе яисә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле вазыйфаларын башкарырга вәкаләтле башка вазыйфаи зат кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итә.

31. Конкурс комиссиясе конкурста катнашкан кандидатларга конкурс нәтиҗәләре турында 7 көн эчендә язмача рәвештә хәбәр итә.

32. Конкурста катнашуга кертелмәгән муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүчеләрнең һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә язмача гариза буенча аларга кире кайтарылырга мөмкин. Әлеге вакыт чыкканчы документлар җирле үзидарә органнары архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

33. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнарны (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) кандидатлар үзләре күтәрәләр.

34. Кандидат конкурс комиссиясе карарына гамәлдәге законнар нигезендә шикаять бирергә хокуклы.